Бисмилләһи - ррәхмәни - ррахим.

Рәхимле, рәхмәтле Аллаһ исеме белән башлыйм. Бу дөньяда бөтен кешеләргә бәхет һәм сәгадәт теләп, соңгы сулышына кадәр дога кылып яшәгән Мөхәммәд галәйһиссәламнең рухына салаватларыбыз ирешсен.

Гайнетдинов Габденур Мулланур улы 1936 нчы елның 5 сентябрендә Бәзәкә авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа 5 яшь тә тулмаган була әле. Әтисе һәм 3 абыйсы бер-бер артлы сугышка китәләр, ләкин әйләнеп кайтмыйлар. Әнисе Нуриәсма, II-группа инвалид, өч бала белән ятим кала. Өченче улы Муллаян авырып үлә. Габденур авыр тормыш шартларында үсеп беренче класска укырга керә, тырышып укый. 1-7 классларны гел “биш”ле билгеләренә генә тәмамлый. Ләкин, укуын дәвам итә алмый, “Сталин”исемле колхозда счетовод булып эшли башлый. Яше җиткәч армия сафларына алына. Аннан кайткач тагын шул ук колхозда бригадир булып эшләвен дәвам итә. 1957 елда “Промартель” дигән оешмада шофер булып эшли башлый. Ә 1968 елдан “Прикамнефть” тә оператор булып эшкә күчә. Тырыш хезмәте өчен күп мактауларга лаек була, шуннан ул лаеклы ялга чыга. Ялга чыккач та авылыбызны газ белән тәэмин итүдә унике ел хезмәт куя. 2004 елда инсульт булып 2008 елда вафат була.

Без Габденур белән 1958 елда өйләнештек. Ун ел торгач, 2 бала булгач, мин Казанда укырга кердем һәм КЗПУ бетердем, ләкин уку буенча эшли алмадым, “Прикамнефть” тә эшләп лаеклы ялгы чыктым. Улыбыз Наиль Казанда укып югары белем алса да “Прикамнефть” тә эшләп лаеклы ялга чыкты. Кызыбыз Наилә Чаллыда почта хезмәткәре.

Кайнанам Нуриәсма Шәйхелислам кызының гыйбрәтле язмышы турында да язып китәсем килә. Ул тумышы белән Минзәлә районы Калмия авылыннан. Аның әтисе Шәйхелислам бабай Минзәлә өязенең баш мулласы була. Колхозлашу елларында аларның бөтен малларын, йорт җиһазларын һәм йортларын колхозчылар талап алып базарда саталар. Бу хәл 1933 елда була. Менә шул чакта Нуриәсма әни Бәзәкәгә кунакка дип килеп Мулланур әтигә димләп кияүгә бирәләр. Әтисе белән әнисе күршеләрнең мунчысында яшәп вафат булалар. 1964 елда без өй салып яткан вакытта шул күрше апа Нуриәсма әнине эзләп килде. Без хәйран булдык, алар бик елаштылар.

Мулланур кайнатамның әтисе Гайнетдин бабай колхозга кергәнче күп атлар тоткан , шул атлар белән авылларга, шәһәрләргә кеше йөрткән.

Бәзәкәгә килен булып төшкәч Нуриәсма әни колхозда эшли. Бервакыт ындырда егылып аягын сындыра, ул озак төзәлми. Күрше Әтәс авылында кешеләрне дәвалаучы әбигә (Шәмсебәнәт әбинең әнисе) алып баралар. Ул, сөяк инде чери башлаган, докторга алып барагыз, ди. Шуннан аны Бондюгта

Чоловский дигән врачка алып баралар. Кызганычка каршы, аякны саклап калып булмый, бер аягын кисеп алалар. Ул вакытта әнигә бары тик 26 , улы Габденурга бер яшь була. Ул шул бер аяк белән көненә өчәр күәс ипи пешереп 20 ел хезмәт куя. Ул вакытта ипине бөтен колхозга 3 кеше пешергәннәр. Шул ук вакытта ярты авылның сепараты да анда була. Бөтен кешенең сөт өсте, чүлмәкләре келәттә торган.

Шундый авыр тормышларда гомер уздырды әни , Габденурны өйләндерде. Кызы Нурзия Чиләбегә барып бухгалтерлыкка укып кайтты да, колхозда бухгалтер ярдәмчесе булып эшләде. Бик тыныч, тату һәм күркәм яшәдек. Аның өч баласы да, безнең балалар да бергә- бергә уйнап үстеләр.

Шулай итеп Нуриәсма әни белән без 40 ел бик тату гомер иттек. Мин килгәндә аңа 45 яшь , миңа 19 яшь иде. Ул 1999 елда 86 нчы яшендә вафат булды. Аллаһының рәхмәтендә һәм урыны оҗмахта булсын.

Мин үзлегемнән гарәп хәрефләрен һәм тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнеп Коръән укыйм һәм алты кешене ислам юлына алып кердем. Аллаһының ярдәме белән Коръән укырга өйрәттем. Татарстан мөселманнары диния назәрәтенең дини оешмасы Менделеев районы мөхтәсибе “Сертификат” бирде.

Бөтен уңыш, сөенеч, бәрәкәт һәм нигъмәтләр кулында булган Аллаһы Тәгаләгә иксез-чиксез рәхмәтләребез булсын.

Мәүгыйдә җиңгинең сөйләгәннәре буенча язам.

Гайнетдин бабай белән Газизә әбинең беренче уллары Мулламехәмәт абый Сиражетдин кызы Мәүгыйдәгә өйләнгәч Ленинградка күченеп китәләр. Нинди эшкә урнашканнардыр, анысын төгәл белмим. 1930 елда беренче кыз балалары Мәрьям дөньяга килә, 1933 елда М-Галия, 1936 елда Камиль , 1939 елда Сания дөньяга килгәннәр. Сугышның беренче көннәрендә үк әтиләре сугышка китә. Күп тә үтми шәһәрдән халыкны эвакуацияли башлыйлар. Ике бүлмәле квартирасын бикләп 4 баласы белән Мәүгыйдә җиңги дә туган якка дип юлга кузгала, поездга утыра. Юлда поезды бомбага тоталар. Андагы мәхшәрне сөйләп тә, язып та бетәрлек булмады дип сөйли иде. Шулай да Мәскәү – Казан юлларын узып ничек кирәк алай авылга кайтып өлгәшәләр. Сугыш беткәнче ул авылда балалар бакчасында няня булып эшли. Сугыш беткәннән соң Ленинградка үз квартирасына кайтып китә, ә Мулламехәмәт абый кайта алмый, сугыш кырында үлеп кала.

Гайнетдин бабайның икенче улы Минһаҗетдин дә сугышка хәтле үк Бондюг химзаводында эшләгән. Ул шуннан китә сугышка һәм әйләнеп кайтмый. Аның да 6 баласы ятим кала. Разия, Зиннур, Мехәмәтнур Чиләбедә яшиләр; Сәетнур, Әдия, Сания авылда гомер итәләр.

Ә Фәрхетдин абыйга сугыш башланганда бары тик 18 яшь тула. Ул да сугышка алына һәм әйләнеп кайтмый - 1944 елда Латвия җирендә вафат була.

Фәния Гайнетдинова


























ГАЙНУТДИНОВ Габденур Мулланурович – оператор обессоливающей и обезвоживающей установки НГДУ "Прикамнефть"

# НАГРАЖДАЕТСЯ
# ПОЧЕТНОЙ
# ГРАМОТОЙ

за высокие показатели в труде и социалистическом соревновании в честь Всесоюзного дня работников нефтяной и газовой промышленности.

Генеральный директор объединения "Татнефть" Р.Т.Булгаков

Председатель Татобкома нефтегазпрофсоюза И.Г.Жжонов

№ 382/29 от 1.08.79г.

ПРОЛЕТАРИИ ВСЕХ СТРАН, СОЕДИНЯЙТЕСЬ!



# ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА

Елабужский горком КПСС и исполком
городского Совета народных депутатов

Н А Г Р А Ж Д А Ю Т

ГАЙНУТДИНОВА ГАБДЕНУРА МУЛЛАНУРОВИЧА

оператора обезвоживающей и обессоливающей установки ЦППН

За высокие производственные показатели, активное участие в общественной жизни и в связи со Всесоюзным днем работников нефтяной и газовой промышленности.

Секретарь
Елабужского горкома КПСС
А.Гунин

Председатель
исполкома горсовета
Е.Привалов

5 сентября
1980 года.

ПРОЛЕТАРИИ ВСЕХ СТРАН, СОЕДИНЯЙТЕСЬ!



# ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА

Награждается победитель в смотре -
-конкурсе за высокую культуру производства и промышленной эстетики

ГАЙНУТДИНОВ ГАБДЕНУР МУЛЛАНУРОВИЧ

оператор ТХУ - I

Начальник
НГДУ "Прикамнефть"

А.М.МУХАМЕТЗЯНОВ.

Председатель группового
комитета профсоюза НГДУ

А.А.САВИН.

2 сентября 1977 года

ПРОЛЕТАРИИ ВСЕХ СТРАН, СОЕДИНЯЙТЕСЬ!

# БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО

ЗДРАВСТВУЙТЕ уважаемые Гайнутдиновы

Габденур Мулланурович и Фания Мифтахутдиновна

Командование войсковой части с радостью сообщает Вам, что Ваш сын Гайнутдинов Наиль Габденурович добросовестно исполняет свой воинский долг перед Родиной, является примером в укреплении воинской дисциплины.

Ваш сын является достойным приемником славных боевых традиций Советских Вооруженных Сил и постоянно помнит Ваш родительский наказ: служить Родине честно, правдиво и добросовестно.

За время службы он имеет 8 поощрений.

ДОРОГИЕ Габденур Мулланурович и Фания Мифтахутдиновна


Командование войсковой части в/ч 89457 выражает Вам глубокую признательность и благодарность за хорошее воспитание сына Наиля

Желаем Вам счастья, хорошего здоровья и успехов в личной жизни на благо нашей любимой Родины.

Войсковая часть 89457

КОМАНДИР ВОЙСКОВОЙ ЧАСТИ [signature]

© Издательство «Плакат». Москва, 1978. Изд. № 9п-212. Тираж 1 800 000 экз. Зак. 6718. Тип. изд-ва «Зоря», г. Дн-ск, ул. Осенняя, 2[illegible]



ГАЙНУІДИНОВ

Габдиннур Мулланурович

оператор ІХУ имени 50-летия СССР

# НАГРАЖДАЕТСЯ

# ПОЧЕТНОЙ

# ГРАМОТОЙ

За высокие показатели в социалистическом соревновании в честь 50-летия СССР.

Начальник
НГДУ "Прикамнефть"
(Б.САПГИР)

★

Председатель группового
комитета профсоюза
(А.САВИН)

Пролетарии всех стран, соединяйтесь!



# ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА

ГАЙНУТДИНОВОЙ

Минефание Мифтахутдиновне

оператору ЦППН

за долголетнюю безупречную работу в НГДУ "Прикамнефть" и в связи с уходом на заслуженный отдых.

| Начальник управления | Секретарь парткома | Председатель профкома |
| --- | --- | --- |
| Н.За[illegible]тдинов | Н.Шакиров | В.Мельников |

## Хөрмәтле ватандаш!

Сезне олы бәйрәм - 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 50 еллыгы һәм фашизмны җиңүгә бәяләп бетермәслек өлеш керткән өчен юбилей медале белән бүләкләнүегез уңаеннан чын йөрәктән котлыйм.

Сезгә искиткеч зур кыенлыклар кичерергә туры килде. Рәхимсез сугышта үлем куркынычы алдында тез чүкмәүләре һәм моңарчы кешелек дөньясы күрмәгән авыр сугышны үз иңнәрендә күтәреп чыкканнары өчен без барлык ветераннарга да олы рәхмәтлебез.

Вакытлар үза, буыннар алмаша. Җиңү көненнән соң да 50 ел үтеп китте. Без һәлак булган геройларның истәлеген яд итәбез, фидакарь хезмәт куйган тыл каһарманнары алдында баш иябез, аларның батырлыклары турында хатирәләрне күз карасыдай сакларга, аларны үзебезнең балаларыбызга һәм оныкларыбызга тапшырырга тырышабыз.

Сезне чын күңелдән шушы мөкатдәс көн белән котлыйм, тиңдәшсез батырлыгыгыз һәм фидакарьлелегез өчен олы рәхмәтемне белдерәм. Сезгә сәламәтлек һәм бәхет телим. Йортларыгызда иминлек һәм татулык булсын, һәрвакыт кешеләрнең, туганнарыгыз һәм якыннарыгызның ихлас кайгыртучанлыгын, турылыгын һәм ихтирамын тоеп яшәгез.

Сезгә тирән ихтирам белән,

Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиев.

Казан, Кремль, 1995 ел.

## Уважаемый соотечественник!

Сердечно поздравляю Вас со всенародным праздником - 50-летием ПОБЕДЫ в Великой Отечественной войне 1941-1945 годов и награждением юбилейной медалью за неоценимый вклад в дело победы над фашизмом.

Вам пришлось испытать величайшее напряжение сил. Мы искренне благодарны всем ветеранам за то, что в жестокой войне Вы не склонились перед смертельной опасностью и сумели на своих плечах вынести такую войну, тяжелее которой не знало человечество. Вы выстояли и победили.

Идет время, меняются поколения. Вот и прошло 50 лет со дня Победы. Мы свято чтим память павших героев, преклоняемся перед тружениками тыла, стараемся бережно хранить и передавать память об их подвигах детям и внукам своим.

От всей души поздравляю Вас с этим светлым днём, выражаю сердечную благодарность за Ваше мужество и самоотверженность. Желаю здоровья и счастья. Пусть в Вашем доме царят мир и согласие, пусть окружают Вас забота и внимание родных и близких, всё то, что украшает жизнь, согревает и наполняет сердца.

С глубоким уважением к Вам,

Президент Республики Татарстан - М.Ш. Шаймиев.

Казань, Кремль, 1995 год.

---

**Первая производительная сила всего человечества есть рабочий, трудящийся.**

**В. И. ЛЕНИН**

# ДИПЛОМ

Тов. ГАЙНУТДИНОВУ Габденуру Муллануровичу

**присвоено звание**

"Заслуженный нефтяник НГДУ "Прикамнефть"

Решение № 100 от 30 августа 19 90

Начальник НГДУ „Прикамнефть"

Председатель профкома

„ПОБЕДИТЕЛЬ СОЦИАЛИСТИЧЕСКОГО СОРЕВНОВАНИЯ 1977 ГОДА"




*Знак учрежден*
*Центральным Комитетом КПСС,*
*Советом Министров СССР,*
*ВЦСПС и ЦК ВЛКСМ*

# УДОСТОВЕРЕНИЕ

Гайнутдинов
Габденур
Мулланурович

от имени *Министерства и ЦК профсоюза*

награжден знаком

„ПОБЕДИТЕЛЬ СОЦИАЛИСТИЧЕСКОГО СОРЕВНОВАНИЯ 1977 ГОДА"

ПРИКАЗ-ПОСТАНОВЛЕНИЕ №63/11

„01" февраля 1978 г.

(подпись) М. П. (подпись)

---

*Пролетарии всех стран, соединяйтесь!*

«Мы придем к победе коммунистического труда!».

*В. И. Ленин.*

НГДУ «Прикамнефть»

# Диплом—свидетельство

Тов. Гайнутдинов Габденур Мулланурович

присвоено звание лучший оператор обезвоживающей и обессоливающей установки

Приказ-постановление № 321

от 19 сентября 1984 года

УПРАВЛЕНИЕ

*Начальник НГДУ „Прикамнефть"*

*Председатель промкома профсоюза*